**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

**КАРАР**

2016 ел, 31 август

№ 603

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы коллегиясе составын раслау турында» 2007 ел, 14 декабрь, 717 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы коллегиясе составына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы коллегиясе составын раслау турында» 2007 ел, 14 декабрь, 717 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2008 ел, 15 февраль, 83 нче; 2008 ел, 25 июнь, 440 нчы; 2008 ел, 21 июль, 518 нче; 2009 ел, 27 февраль, 114 нче; 2010 ел, 11 гыйнвар, 2 нче; 2010 ел, 16 сентябрь, 741 нче; 2011 ел, 26 декабрь, 1067 нче; 2014 ел, 12 апрель, 235 нче; 2014 ел, 17 ноябрь, 883 нче; 2015 ел, 4 февраль, 58 нче; 2015 ел, 6 апрель, 223 нче; 2015 ел, 30 октябрь, 818 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы коллегиясе составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

коллегия составыннан Р.Ф.Вәлиулловны чыгарырга;

коллегия составына Кузнецов Артём Александровичны – Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының Миграция мәсьәләләре буенча идарә башлыгын кертергә (килешү буенча);

Захаров Борис Федорович вазыйфасы исемен түбәндәге редакциядә бәян итергә:

«Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль

яклау министрлыгы каршындагы Иҗтимагый совет рәисе, «Хезмәт һәм социаль мөнәсәбәтләр академиясе» югары һөнәри белемнең һөнәр берлекләре белем бирү учреждениесенең казан филиалы директоры киңәшчесе.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков